# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Кызыл-Мишә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

25.08.2022 № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына таянып, 2022 елның 25 августында узган гражданнар җыенында «2023 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Кызыл-Мишә торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Кызыл-Мишә торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- күмү урыннарын карап тоту: ТР Саба муниципаль районы Кызыл-Мишә т. п. зираты территориясен коймалап алу (агач коймаларны сүтү, металл баганалар урнаштыру, профильләрне монтажлау, капкалар урнаштыру, металл өслекләрне буяу, металл штакетниклар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 240 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 130 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 130 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Кызыл-Мишә торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.
2. “2023 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Кызыл-Мишә торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Кызыл-Мишә торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә

килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) күмү урыннарын карап тоту: ТР Саба муниципаль районы Кызыл-Мишә т. п. зираты территориясен коймалап алу (агач коймаларны сүтү, металл баганалар урнаштыру, профильләрне монтажлау, капкалар урнаштыру, металл өслекләрне буяу, металл штакетниклар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тимершык авыл җирлеге башлыгы

А.Х. Хаҗиев